КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 31 июль г.Казань № 533

2016 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектларының халыкка социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту, картлык буенча һәм инвалидлык буенча иминият пенсияләре алучы эшләмәүче пенсионерларга адреслы социаль ярдәм күрсәтү һәм эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле социаль программаларын финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2011 ел, 10 июнь, 456 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2017 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру тәртибен;

2017 елда эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укыту белән бәйле Татарстан Республикасы социаль программасын тормышка ашырганда барлыкка килә торган Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Пенсия фонды бюджетыннан субсидияне тоту тәртибен.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын 2017 елда Татарстан Республикасында яшәүче эшләмәүче пенсионерларны компьютер белеменә укытуны оештыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы итеп билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин